| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ** |
| **С О В Е Т**<br>**Нижнекамского муниципального района** | **Түбән Кама муниципаль районы**<br>**С О В Е Т Ы** |
| 423570, г.Нижнекамск, пр.Строителей,12<br>тел./факс (8555) 41-70-00 | 423570, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12<br>тел./факс (8555) 41-70-00 |


**Р Е Ш Е Н И Е** **К А Р А Р**

**№ 25** **11 апреля 2019 года**

Түбән Кама муниципаль районы Советының 2016 елның 20 октябрендәге «Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын төзүче, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм оешмаларга озак сроклы нигездә куллануга тапшыру өчен һәм (яки)куллану өчен билгеләнгән, өченче затларның хокукларыннан (кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) ирекле муниципаль милек исемлеген раслау турында» 55 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясындагы 4 өлеше, «Дәүләт милкендә яисә муниципаль милектә булган һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан арендалана торган күчемсез милекне читләштерү үзенчәлекләре һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» (үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) 2008 елның 22 июлендәге 159-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Түбән Кама муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама муниципаль районы Советының 2016 елның 20 октябрендәге «Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын төзүче, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм оешмаларга озак сроклы нигездә куллануга тапшыру өчен һәм (яки) куллану өчен билгеләнгән, өченче затларның хокукларыннан (кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) ирекле муниципаль милек исемлеген раслау турында» 55 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

«(кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш)» сүзләрен «(хуҗалык алып бару, оператив идарә итү хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш)» сүзләренә алмаштырырга.

2. Түбән Кама муниципаль районы Советының 2016 елның 20 октябрендәге «Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль

берәмлегенең кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын төзүче, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм оешмаларга озак сроклы нигездә куллануга тапшыру өчен һәм (яки) куллану өчен билгеләнгән, өченче затларның хокукларыннан (кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) ирекле муниципаль милек исемлеген раслау турында» 55 номерлы карары кушымтасына,  әлеге карарга кушымта нигезендә мөлкәте белән тулыландырып, үзгәрешләр кертергә.

3. Әлеге карарны гаммәви мәгълүмат чараларында һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны социаль-икътисадый үсеш, бюджет-финанс мәсьәләләре һәм муниципаль милек буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама муниципаль районы
Башлыгы А.Р. Метшин

Түбән Кама муниципаль районы
Советының
2019 елның 11 апрелендәге
25 номерлы карарына
кушымта

| т/с | Исәпкә алу объектының исеме | Адрес (урнашу урыны) | Объектның характеристикасы, мәйданы, кв. м. | Чикләүләр (мәшәкатьләр) булган очракта аренда рәвешендә | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Оештыру-хокукый формасын күрсәтеп, арендатор исеме | Шартнамә буенча максатчан билгеләнеш | Аренда шартнамәсе төзү датасы | Аренда шартнамә сенең гамәлдә булу срогы, ай | Аренда шартнамәсе-нең гамәлдән чыгу датасы |
| 1. | 16:53:040406:3562 кадастр номерлы 1001номерлы торак булмаган бина | Түбән Кама шәһәре, Корабельная ур., 8 | 136,6 мәйданлы бинаның 2 катындагы торак булмаган урын | "ҖТКХ-2" ҖЧҖ | офис | 05.08.16 | 36 | 04.08.19 |
| 2. | 16:30:060201:1471/1 кадастр номерлы 1005 номерлы торак булмаган бинаның өлеше | Түбән Кама районы, Красный Ключ п., Бакчалы ур., 2, 1005 ур. | Административ бинаның (39-42 номерлы) 2 катындагы 41,6 мәйданлы ЧП1 | «Красный Ключ» ИК | офис | | | |

Түбән Кама муниципаль районы
Башлыгы урынбасары Э.Р.Долотказина